| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.11.2019 Казан шәһәре № 10-96/кс

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 07.12.2018 № 10-135/кс карарына һәм «РТЮ» ААҖ филиалы – Җылылык һәм су белән тәэмин итү буенча үзәк дирекциянең структур бүлекчәсе – Горький дирекциясенең Казан территориаль участогы өчен әлеге карарда билгеләнгән салкын суны транспортлау буенча озак сроклы тарифларга үзгәрешләр кертү турында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2020-2023 елларга салкын суны транспортлауга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай табышына төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2019-2023 елларга «РТЮ» ААҖ филиалы – Җылылык һәм су белән тәэмин итү буенча үзәк дирекциянең структур бүлекчәсе – Горький дирекциясенең Казан территориаль участогы өчен салкын суны транспортлауга һәм агынты суларны транспортлауга тарифлар билгеләү турында» 07.12.2018 № 10-135/кс карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

аталышында «һәм агынты суларны транспортлау» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «һәм агынты суларны транспортлау», «һәм агынты суларны агызу» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктта «һәм агынты суларны транспортлау», «һәм агынты суларны агызу» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктта «агынты суларны агызу» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 07.12.2018 № 10-135/кс карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2019 № 10-96/кс карары редакциясендә)

## 2019-2023 елларга салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыра торган «РТЮ» ААҖ филиалы – Җылылык һәм су белән тәэмин итү буенча үзәк дирекциянең структур бүлекчәсе – Горький дирекциясенең Казан территориаль участогы өчен салкын суны транспортлауга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Салкын суны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | |
| 1 | «РТЮ» ААҖ филиалы – Җылылык һәм су белән тәэмин итү буенча үзәк дирекциянең структур бүлекчәсе – Горький дирекциясенең Казан территориаль участогы (тарифлар өстәлгән хак бәясен исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 9,96 |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 15,18 |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 15,18 |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 15,40 |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 15,40 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 15,87 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 15,87 |
| | | 01.07.2022 башлап | 16,17 |

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Салкын суны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | | 31.12.2022 кадәр | |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 16,17 |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 16,67 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 07.12.2018 № 10-135/кс карарына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2019 № 10-96/кс карары редакциясендә)

## 2019-2023 елларга салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыра торган «РТЮ» ААҖ филиалы – Җылылык һәм су белән тәэмин итү буенча үзәк дирекциянең структур бүлекчәсе – Горький дирекциясенең Казан территориаль участогы өчен салкын су транспортлауга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрлары

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «РТЮ» ААҖ филиалы – Җылылык һәм су белән тәэмин итү буенча үзәк дирекциянең структур бүлекчәсе – Горький дирекциясенең Казан территориаль участогы | | | | | | |
| 1.1 | салкын суны транспортлауга | 2019 | 2 157,87 | 1 | - | - | 0,343 |
| | | 2020 | 2 200,39 | 1 | - | - | 0,343 |
| | | 2021 | 2 258,98 | 1 | - | - | 0,343 |

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| | | 2022 | 2 325,85 | 1 | - | - | 0,343 |
| | | 2023 | 2 394,70 | 1 | - | - | 0,343 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге